**СОВЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**01 март 2019 нчы ел** **Мәлки авылы** **№ 2**

2017 елның 06 апрелендәге 4 нче номерлы
Татарстан Республикасы Мәлки авыл җирлеге
Советы карары белән расланган
«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге территориясен
төзекләндерү кагыйдәләренә узгәрешләр
һәм өстәмәләр керту турында.

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы «Федераль законга узгәрешләр керту турында»гы 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясенең аерым закон актлары, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндеру объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга карата бердәм таләпләр билгеләү максаты нигезендә, Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1, 2017 елның 06 нче апрелендәге 4 нче номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә тубәндәге узгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче булектәге 6 нчы пунктның 4 нче һәм 63 нче абзацларын тубәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территорияне төзекләндерү- әлеге кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм гражданнарның яшәү шартларын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен

һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы — территорияләрне, жир кишәрлекләрен, — биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлтелгән.

Тезеклэндерү элементлары — декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җихазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре һәм шул исәптән биналар, корылмалар фасадлары, кече архитектура формалары капиталь стационар булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм курсәткечләр территорияне төзекләндерунең состав өлешләре буларак кулланыла».

1.2. Ш нче булектәге 27 пунктны түбәндәге эчтәлекле 27.1 пункт асты белән тулыландырырга:

«27.1 Йорт билгеләрендә, тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәулэт телләре турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да кубрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш, дөрес һәм ачык итеп эшләнгән булырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл жирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http:// molkeev -kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Мәлки авыл җирлеге башлыгы : Ф.П.Поляков**